# Харрас Әюп шигъриятендә автор күзаллаулары эволюциясе

Харрас Гыйльмегали улы Әюпов 1946 елның 21 августында Татарстанның Мөслим районы Түреш авылында колхозчы гаиләсендә туган. Түрещ, Күбәк мәктәпләрендә белем алганнан соң, 1964 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә.

Харрас Әюпнең хезмәт биографиясе 1969 елда Мөслим район газетасы «Авыл утлары» редакциясендә башлана, ул анда иң элек – өлкән әдәби хезмәткәр, соңрак авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире булып эшли, ә инде 1970-1971 елларда комсомол райкомында – икенче секретарь һәм «Камдорстрой» тресты комсомол комитетында секретарь вазифаларын башкара.

1972 елдан алып Х. Әюпнең иҗат һәм тормыш елъязмасы Казанда языла. Башкалага күченеп килгәннән алып 1983 елның декабренә кадәр ул – «Татарстан яшьләре» газетасында, шуннан соң Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият редакциясендә эшли, ә инде 1994 – 2007 еллар аралыгында нәшриятның баш редакторы хезмәтендә.

Харрас Әюп тәүге шигырьләрен алтмышынчы еллар башында яза, алар еш кына көндәлек  матбугатта да басыла. Университетта укыганда шактый актив иҗат итсә дә, «Ышаныч» дип исемләнгән беренче мөстәкыйль җыентыгы 1980 елда гына дөнья күрә. Әлеге китапта шагыйрьнең әдәби кыйбласын, калыплашкан стиле инде ачык тоемлана. Харрас Әюп тәнкыйтьтә алтмышынчы елларда татар поэзиясенә яшь каләмнәр иҗаты белән килеп кергән яңарышны дәвам итүчеләрнең берсе буларак телгә алынгаласа да, аны милли әдәби традицияләрне эзлекле, өзексез агымда үстерүчеләрнең берсе санарга кирәк.

Өлгергән шагыйрь Харрас Әюпның әдәби сандыгында нәкъ дистә китап: «Кояшлы яңгыр» (1983), «Каен балкышы» (1985), «Таң суы» (1987), «Төнге кояшлар» (1989), «Сабыр савытлары» (1992), «Биш вакыт намаз» (1995), «Җәяүле буран» (1996), «Көй эзләү» (2001), «Ут аркылы сикерү» (2004), «Йөз яктысы» (2005).

Харрас Әюп шигъриятенә үзен яраткан, үстергән туфракка чиксез мәхәббәтне тирәннән, күңел түрләреннән килүче нечкә хисләр аша җиткерә. Беренче әсәрләреннән үк ул, туган ягын тасвирлаганда, үзе яшәгән чор атмосферасын тәфсилле чагылдыра; аларда сугыш елларында, аннан соң туганнарның тарихка, ата-анага, иҗтимагый барышка мөнәсәбәтләре ачык чагылыш таба.

Харрас Әюпов иҗат иткән үсмер егетнең авылдан шәһәргә китүен аның мәшәкатьләреннән качу дип түгел, ә яшьлек хыялларына иярү дип санарга кирәк. Ул, каланың таш урамнарыннан атласа да, анда дөньяга карашларын киңәйтсә дә, авылны һәм табигатьне тыңлый, анда яшәүчеләрнең, һәрбер җан иясенең проблемаларын алга куеп яза, аның шигъри авазларына – табигыйлеккә якынаерга омтыла:

Рөхсәт ителмәгән миңа
Арттырулар, киметүләр:
Сүзләремдә һәр бөҗәкнең
Ышанычы-өмете бар.

Каян алыйм, ниләр языйм?–
Язмыйм инде… Тыңлыйм бары.
Тыңлыймын да үз телемә
Күчерәмен мин дөньяны.

(Язмыйм инде…)

Харрас Әюпның бөтен иҗатын өлкәннәр кичергәннәрне аңларга тырышу, халык тәҗрибәсен, акылын яшь буыннарга әйтеп калдыру омтылышы бер җепкә бәйли шикелле. Бу тәүге китапларына тупланган шигырьләренең исемнәрендә үк («Әтиләр тавышы», «Амәнәт», «Йөз яшәр карт белән очрашу» «Җирдән киткәннәр сүзе»), фольклор мотивларына мөрәҗәгать итүендә («Кышкы Идел өстендә», «Туры сүзгә», «Терек суы»), олылар башкарган гамәлләрне, киңәшләрне бәяләп язуында, яшьләрнең кылганнарын алар янәшәсенә куеп каравында («Әби, ут бир!..», «Әткәй белән

сөйләшү») да күзәтелә. Ул тасвирлаган авыл – Рәсәйнең гадәти бер авылы түгел, әлегә гореф-гадәтләрен, дөньяви барышка карашын, фәлсәфәсен, вакыт агышын, хезмәт ритмын саклаган җанлы татар авылы.

Харрас Әюповның бу чор әсәрләре, үзенчәлекле образлар ярдәмендә иҗат ителсә дә, аларда күпчелекнең башы җитмәслек катлаулы абстракцияләр юк, ул тормыш фәлсәфәсен үткәндәге һәм көндәлектәге күренешләрнең асыл мәгънәсен ачу аша тудыра:

Алларымда җыелып бетмәс

Җиләклек яткан кебек,–

Баш орам,

Шул җиләклектә

Кыйбламны тапкан кебек.

(Җиләк җыю)

Табигать, хезмәт, бәйрәм һәм көндәлек ял, уйланулар, яшәү, вакыт мелодиясен бөтен нечкәлекләрендә яңгырата алган Харрас Әюпов шигъриятенең фәлсәфәсе көчле лиризм белән үрелә:

Әй, асыл яр! Кирәкми лә еларга,

Болай да бит моңсу әле елларга:

Дөнья буйлап инде әллә кайларга

Сибелгәннәр чулпыларың, җырларың!

(Чулпылар)

Харрас Әюпов иҗат иткән мәхәббәт шигырьләре фаразларга бай, ул хәтта өзелгән мөнәсәбәтләрнең дә киләчәк сызымнарын биреп язарга ярата:

Һәм мәхәббәт

Гомерләр үтәсе,

Без дә бер китәсе,

Барасы юлыбыз билгеле…

Сеңәрсең су булып,

Үсәрсең гөл булып,–

Барыбер табарсың син мине…

(Барыбер табарсың)

Сиксәненче елларда дөнья күргән «Ышаныч», «Кояшлы яңгыр», «Каен балкышы», «Таң суы» җыентыклары Харрас Әюпов иҗатында аерым бер этапны чагылдыра. Аларны кече күләмлелек, идея-тематик һәм интонацион уртаклык берләштерә. Якты мизгелләрнең хәтер сандыгына күчә баруы, үзеңә якыннарны югалту, ил югалтулары турында уйланулар Харрас Әюп әсәрләрен инде тагын да тирәнрәк моңга төрә. Югалтулар аркасында хәсрәтләнү яисә истәлекләргә бирелгәндә сагышка тару артыгракка да китә шикелле, әмма шунысы ачык: әлеге сыйфат аның иҗатын үзенчәлекле, мәгънәле һәм хисси итә. Шул ук вакытта алда телгә алынган китапларның исемнәре шагыйрьнең торгынлык еллары поэзиясе тормышта, күңелдә яктылыкка урын барлыгы, лирик геройны яшәткән өмет, аның көче турында сөйли.

Харрас Әюповның шигырьләре, бик аз чыгармалар белән, хәтта тыныш билгеләре ярдәмендә белдерелмәгәндә дә, тойгылы интонацияләрдә тәмамлана. Алар автор миненең лирик характерын, фәлсәфәгә бирелүчәнлеген ачык чагылдыра:

Кемгә дәва – Ватан, кемгә – яра…
Төзәтәлмәс вакыт арасы –
Илдән киткәннәрнең йөрәгендә
Иле кадәр була ярасы!..

(Үләннәр дә уйланыр чак)

Харрас Әюповның «Сабыр савытлары» җыентыгына кергән әсәрләре, сиксәненче еллар ахырында язылса да, эчке рухы, үзәккә куелган тематикасы, идея мотивлары һәм шуларга бәйле рәвештә барлыкка килгән кайбер форма үзгәрешләре белән, аннан соң басылган «Биш вакыт намаз» поэмасына (1995), «Җәяүле буран» (1996) җыентыгына тупланган әсәрләренә якынрак тора. Аларда тарихка, милләт язмышына карата фикерләр калкулана; зур темалар, проблемалар күтәрелә; һәм әлеге үзгәрешләрнең

алшарты һәм сәбәпләре – әлбәттә, узган гасыр ахырында барган илдәге, бигрәк тә Татарстандагы иҗтимагый-сәяси барыш. Шагыйрь 1988 елда язылган «Авыл җаны» поэмасын шундый юллар белән башлый да:

Гел башкада иде юкса ният,
Тел чишелгән заман, ниләр язмам!–
Калыкты да ачы төер булып,
Кемдер алды кебек бугазымнан.

Харрас Әюпнең соңрак басылган «Ут аркылы сикерү», бигрәк тә «Йөз яктысы» китаплары иҗатының һәр баскычына да караган, каләмдәшләре, шагыйрьнең үз тарафыннан югары бәяләнгән әсәрләрен туплаган, һәм алар аша Харрас Әюпнең иҗат кредосын, туксанынчы-икемеңенче елларда татар шигърияте ирешкән биеклекләрне билгеләп була.

Илдә барган үзгәртеп кору вакыйгалары Харрас Әюп иҗатын, чын-чынлап, икегә бүлеп куйгандай итә. Билгеле ки, аның үзенә хас язу стиле үзгәрми, шагыйрьнең фикри офыклары киңәя. Бу хакта сиксәненче елларның икенче яртысында поэма жанрындагаы уңышлары күрсәтеп тора. Яңа поэтик сулышы ачылгандай, шигырь жанр формасында да актив эшләргә тотынган Харрас Әюпов, әлбәттә, фикерне киңмассаларга ирештерү, тормыш вакыйгаларын киңрәк ачу, заман күренешләрен күбрәк кертү һәм иҗтимагый барышны тулырак чагылдыру мөмкинлекләре зур булган күләмле формаларда сынамый кала алмый. Аның «Көзге» (1987), «Авыл җаны» (1988), «Көй эзләү» (1988), «Йөрәк атым» (1988), «Су хәтере» (1989), «Биш вакыт намаз» (1994) кебек заман проблемаларын ачык чагылдырган әсәрләрен әдәби җәмәгатьчелек яратып кабул итте.

Харрас Әюпов, “Игенче турында баллада”, “Капка баганасы турында баллада” кебек тирән мәгънәле әсәрләре белән, узган гасыр ахыры татар әдәбиятында баллада үсешенә үзеннән өлеш кертте. Шагыйрьнең драматик сюжетлы һәм эмоциональ-экспрессив буяулы формаларга мөрәҗәгать итүе шулай ук гомумстиль сыйфатлары белән билгеләнә иде.

Харрас Әюпнең эпик поэзиясе һәм шигырьләре арасында тыгыз бәйләнеш күзәтелә, ул илһамының поэмалар яздырырлык саф чишмәләрен дә авылда таба, чөнки табигатькә якын торган авыл кешеләре арасында шартлылыкка урын юк, мөнәсәбәтләр гади һәм ачык икәнлекне аңлап эш итә.

Икенче яктан, татар авылы – милләтнең киләчәге, ул – телебезнең бишеге, татарның рух сандыгы. Үзәккә лирик миннең иҗтимагый-сәяси-тарихи барышка бәйле формалашкан күңел конфликтын куючы «Авыл җаны» поэмасында шагыйрь, кайтып-кайтып, әнә шул фикерләрне уздыра. Әсәр герое инде тәмам югалып барган, аерым-аерым кешеләр сыйфатында бөтен илгә сибелгән авылының йөрәген үз җанында йөртә, «шәһәр сөреме»ндә аның сафлыгы югалудан гаҗизләнә. Аның белән авыл арасында әле өзелеп үк бетмәгән нечкә генә җеп бар. Лирик мин еш кына без исеменнән сөйли. Фикерләү ноктасын шул рәвешчә үзгәртү геройны авыл кешеләренең, аннан китеп шәһәрләшүчеләрнең, шул шәһәрләшүгә, ниһаять, үзендә каршы тора алырлык көч табучыларның аерылмас бер кисәгенә әверелә, фикер ассызыклана, көчәя, аның гомумилек сыйфаты арта.

«Авыл җаны» поэмасында урталыктагы социаль катлам психологиясе тудырыла. Авыл һәм шәһәр арасында торучы, психологик күчеш чорын кичергән, көчле холык сыйфатларына ия булган әлеге геройлар торгынлык еллары татар прозасында аеруча Г.Ахуновның хезмәт темасына язылган әсәрләре аша калкуланды, ныгыды һәм әкренләп эпик поэзиягә дә үтеп керде. Әлбәттә, ул аның ераграк башы герое «ике мин» арасында бәргәләнгән яисә авылдан чыгып «кеше булган» Һади Такташ һәм аның мәктәбе тарафдарлары поэзиясенә барып тоташа иде.

«Авыл җаны» поэмасында тарихның фаҗигале битләренә ишарә күп, һәрбер заман шәхесенең драмасы көчле. Шәһәрдә җанына урынын тапмаса да, картлыгын кичергән әнкәйләр, авылын югалткан яшь буын һәм шулар арасында торган лирик мин. Ул олы буын белән михнәтле, җитешсез чорларны узган, ул яшь буын белән кешелексез, җаннарны берләштергән

җырсыз-бәйрәмсез киләчәккә атлый. Ул бер үк вакытта элекке һәм бүгенге авылның контраст күренешләренә шәһәр һәм авыл каршылыкларына караганда да ныграк борчыла.

Сиксәненче елларның ахырыннан алып Харрас Әюпның шигъриятендә бер-бер артлы югалтулардан туган сагыш хисе көчәйгәннән-көчәя, герое үз халәтен җиткерерлек көй-мотивлар эзләү белән тагын да күбрәк мәшгуль, шуңа күрә әсәрләренә туган тел, моң, бишек җыры кебек төшенчә-гыйбарәләр һәм җанга кадерле затларны, хәтердә күңел тибрәткеч мизгелләрне барлау мотивы әледән-әле килеп керә.

Шагыйрь үзенең һәрдаим эзләнүләрен, юксынуларын, шуларны җиткерерлек аһәңнәрен тыгыз сыйдырышлы көй эзләү гыйбарәсе аша атый, һәм әлеге гыйбарә аның иҗат лабораториясен, лирик мииненең эчке рухын, иҗатын тулаем ачарлык атама булып тора ала. Әлеге мотив Харрас Әюп кече күләмле шигырьләренең структурасына да йогынты ясый: шагыйрь аны төрле калыптагы сораулар рәвешендә куя, еш кына соңгы строфаларда аңа янәшә торырлык, аны ачарлык, тәгаенләштерерлек яисә шул эзләүнең нәтиҗәсе булган фикерләр уздыра; сюжет сызыгы эзләнүчән геройның шәхес буларак үсешен, кыйммәтләр барлавын, әмма милләтнең рухи сандыгына бәйле югалтуларын гәүдәләндерүгә хезмәт итә.

Харрас Әюп каләменнән чыккан иң тәэсирле поэмаларында герое шулай ук эзләгәнен бүгенге тормышыбыздан тапмый. Турыдан-туры «Көй эзләү» дип исемләнгән әсәрендә шагыйрь илебезне, милләтебезне уйналмаган гармунга тиңли. Асмәгънәгә һәм күпфикерлелеккә корылган әлеге поэма Үзгәртеп кору елларындагы кыйбла эзләүне, иманга кайтырга омтылышны, татар халкы һәм аның бер баласы булган шагыйрь күңелендәге кузгалышларны ачык тасвирлый.

Хәррас Әюп – чын мәгънәсендә лирик поэмалар остасы. Аның шул яссылыкта ачылып китәчәген тәүдә язылган «Көзге» поэмасы ук сөйли иде инде. «Су хәтере», «Бишвакыт намаз», «Йөрәк атым» поэмаларының шулай ук тарих һәм тарих тәгәрмәчендә әйләнгән, изелгән, көчкә сакланып калган

татар милләте, вакыт һәм шул вакытта гомер агышы, яшәеш һәм аның аерым күренешләрдә чагылышы турында уйланулар нәтиҗәсендә туганлыгы ачык аңлашыла. «Су хәтере»ндә тарихи фактларга, детальләргә мөрәҗәгать, дәлилле фикер тагын да арта төшә.

Дәүләтчелек идеясен калкуландырган «Базарлар» поэмасы контраст тасвирлар һәм янәшәлекләр алымына корылган. Төп стиль линиясе шагыйрь тарафыннан публицистик дип билгеләнсә дә, лиризм элементлары зур урын алганлыктан, яңгырашы, төп интонациясе белән ул алдагы эпик әсәрләреннән аерылмый диярлек. Болардан тыш аның шул ук вакытта шагыйрь иҗатында күтәрелгән милли тематиканы дәвам итүен дә әйтергә кирәк.

Поэмада бүгенге базарлар мөстәкыйль ил булып яшәгән Болгарның затлы товарлар белән сату итеп ил данын күтәргән «Ага базары» яшәү бәяләренең артуын хәбәр иткән «колхоз базары»на, кеше язмышларын хәл иткән «коллар»ныкына, ярымколлык хәлендә яшәгән халыкларның байлыгын бүлешү урынына әверелгән һәм шартлы «дөнья базары»на һәм башкаларга каршы да, янәшә дә куела.

Нинди генә базар турында язса да, шагыйрь түбәндәге фикерләргә килеп чыга: «Илдә кол булмыйча калган кеше сирәк», «Ил базарында кешенең бәясе юк». Лирик мин үзен, беренче чиратта, туган туфрагында яшәгән татар кешесен, «конституцион богау кигән» «ирекле кол» дип бәяли. Әсәр, үзгәреп килгән Рәсәй шартларыннан чыгып караганда да, кыю фикерләр уздыра, иҗтимагый-сәяси проблемаларны бөтен үткенлеге белән куя.

Поэманың  башка кисәкләрен каймалап торган «Базарга бару» һәм «Базардан кайту» өлешләре эпик прозаның эпилог һәм прологларына тартым. Базарлар буйлап сәяхәте башланган бүлектә лирик герой алдан ук аларның намус сатылырлык бер урын икәнлеген искәртеп куйса, соңгысында милләтләрнең тарих чылбырыннан төшеп калырга мөмкинлеген образлы фикер ярдәмендә җиткерә:

…Гомер – кыйбат!

Аңа да бит чират…

Чиратыңны берүк югалтма.

Лаексыз рәвештә яшәтү хокукына ия булган милләтләр иҗтимагый-тарихи базарларда икенчеләргә гомер сата, ди шагыйрь. Соңгы строфларны укыганда, беренче бүлектә яңгыраган фикерләргә дә әйләнеп кайту, шушы вакытта сатучы да, алучы да күпмедер дәрәҗәдә намус сатырга мөмкин, дигән нәтиҗәгә киленә. Шагыйрь укучының үзен абстракцияле фикер йөртүгә этәрә.

Харрас Әюп иҗатын лирик геройны тудыру алымнары, өстенлек иткән моңсу аһәң, үтәли фикри мотивлар бөрбөтен итә. Соңгылары, нигездә, милләтнең үткәне һәм бүгенгесе, көндәлек тормышы һәм теле, гореф-гадәтләре, милләтнең генофонды булган авыл тормышына кагылышлы хәл-күренешләр аркылы туа, үстерелә, көчәйтелә һәм, үзара тыгыз үрелеп ,зур бер теманы – милләт язмышын ачуга хезмәт итә. Әлеге язмышка милли рухлы шәхес, халыкны аңлаудан ерак торган һәм аңа омтылмаган да җитәкчелек, вак проблемалардан арына алмаган гадәти бер кеше, рухи тамырларсыз калудан курыккан әдип, авылда яисә шәһәрдә, мегаполиста яшәүчеләр мөнәсәбәте; милли барышта һәркайсының роле; ул барышның тармаклары һәм яссылыклары – боларның берсе генә дә Харрас Әюпнең һәм шигырьләрен, һәм поэмаларын читләп үтми.

Харрас Әюпнең тирән эчтәлеккә ия һәм форма ягыннан да камил «Сиңа гына язган хатлар» (Л.Батыр-Болгари муз.), «Кайда син, гармун?», «Миләш» (З.Хәйретдинов муз.), «Исемеңне язган идем» (Р.Хәсәнов муз.), «Гомерләр узып бара», «Ай-һай, дөнья...» (М.Шәмсетдинова муз.), «Чакыру» (Г.Мингалиев муз.), «Авыл карчыклары» (Р.Вәлиев муз.) шигырьләре, танылган композиторлар тарфыннан көйгә салынып, озак еллар дәвамында җырландылар һәм булдыра алганча татар эстрадасын түбән зәвыклылыктан саклауга хезмәт иттеләр.

Харрас Әюпка әдәбият-сәнгать үсешенә керткән хезмәте өчен 1994 елда «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән

мактаулы исем бирелде. Ул Җамал Вәлиди премиясе иясе иде. Аның иҗаты мәртәбәле Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә тәкъдим ителде. Шагыйрь вакытсыз, иҗатының яңа баскычларга күтәрелгән бер чагында – 2008 елның 7 октябрендә арабыздан китеп барды.

**Китаплары**

**Ышаныч:** Шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр.,1980.

**Кояшлы яңгыр:** Шигырьләр. —Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.

**Каен балкышы:** Шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.

**Таң суы:** Шигырьләр. —Казан: Татар. кит. нәшр.,1987.

**Төнге кояшлар:** Шигырьләр, поэмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр.,1989.

**Сабыр савытлары:** Шигырьләр, поэмалпр. — Казан: Татар. кит. нәшр.,1992.

**Биш вакыт намаз:** Поэма. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.

**Җәяүле буран:** Шигырьләр, побиив&юр /Ф.Зөлкарнәй кереш сүзе белән («Шигырь китапханәсе» сериясе). — Казан:: Татар. кит. нәшр., 1996. —

**Көй эзләү:** Поэмалар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.

**Ут аркылы сикерү:** Шигырьләр, поэмалар. —Казан: «Мәгариф» нәшр., 2004.—175 6.

**Йөз яктысы:** Шигырьләр, поэмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.

* * *

**Ташка язгандар һөйөүзе:** Шигырьләр, поэмалар /Башкорт телендә.– Өфө: Башкорт, кит. нәшр.. 1994.

**Аның турында**

Гайнетдинова Д. **Ак кәгазьдә күңел нуры** // Татарстан яшьләре. — 1981. — 13 гыйнв.

Гыймадиев И. **Шагыйрь күңеле** // Соц. Татарстан. — 1990. — 2 нояб.

Мостафин Р. **Сабыр савытлары бар икән** // Казан утлары. — 1994. — № 3. — 158-160 б.

С и б а т Р. **Гомерлек аргамак** // Ватаным Татарстан. —1994. — 29 июль.

Галимуллин Ф.. **Яшен лисенндп...** //Шәһри Казан.— 1995. — 24 март.

Вәли Р. **Гомерләрнең ойлә туры җиткән...** // Шәһри Казан. — 1996. — 23 авг.

Әхмәтҗанов М. **«Нәселемнең мин бер тәрәзәсе**.....//Мәдәни җомга. — 1996. — 5 июль.

Зөлфәт. **Тыелгысыз кош сере** // Казан утлары. — 1996. — № 8. — 78 б.

Харрасова Р. **Шагыйрь җанына ни җитми?** / Х. Әюп белән әңгәмә // Мәгърифәт. —1996. — 1 6 авг.

Рәдиф Гаташ. **Тын, илаһи гыйбадәт**//Ватаным Татарстан.— 1996. — 20 авг.

Әхмәтҗанов М. **Без** — **Кояштан** // Татар иле. — 1996. — 31 авг.

Минһаҗ Р. **Дөньялардан узып барган чакта йөрәк атларыңны югалтма //** Ватаным Татарстан,– 1996.– 9 окт.

Поварисов С. **Ташка язылган мәхәббәт** // Кызыл таң (Уфа). — 1997. — 6 авг.

Бакиров М. **Күкрәгеңдә көең исән булсын** // Мәдәни җомга. — 2005. — 15 апр.

Шәмсутова А. **«Сискәндереп гамьсез көнне...»:** Харрас Әюпов иҗаты турында уйланулар // Казан утлары. — 2006. — № 1. — 115-119 б.